ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.03.2024 Олы Кайбыч авылы № 99

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 28 февралендәге карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында «Гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына кабул итү турында гаризалар кабул итү» муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының «Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының 2020 елның 2 сентябрендәге 458 номерлы боерыгы белән расланган башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 30 августындагы 642 номерлы боерыгы, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының АБ-3389/10 номерлы, Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең «Балаларны укытуны оештыру турында» 2022 елның 3 ноябрендәге 02-333 номерлы хаты, Россия Мәгариф министрлыгының 2022 елның 4 апрелендәге 03-442 номерлы , 2022 елның 6 апрелендәге 03-462 номерлы хатлары нигезендә, Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 28 февралендәге 61 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында «Гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына кабул итү турында гаризалар кабул итү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 1 бүлекнең 5.1 пункты 1.5.1 пунктчасына на түбәндәге эчтәлекле 1.5.1.1 пунктчасы өстәргә:

«1.5.1.1. Дәүләт һәм муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында «Хәрби хезмәткәрләр статусы турында» 1998 елның 27 маендагы 76-ФЗ номерлы Федераль законның 24 статьясындагы 8 пунктында һәм «Россия Федерациясе

милли гвардия гаскәрләре турында» 2016 елның 3 июлендәге 226-ФЗ номерлы Федераль законның 28.1 статьясында күрсәтелгән балаларга, гаиләләренең яшәү урыны буенча дәүләт һәм муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында чираттан тыш урыннар бирелә.».

- 2 бүлекнең 2.6 пунктын түбәндәге эчтәлекле 2.6.7 пунктчасы белән тулыландырырга:

«2.6.7. Хәрби хәл кертелгән Донецк халык республикасы, Луганск халык республикасы, Запорожск һәм Херсон өлкәләреннән килгән балаларны гадәттән тыш хәлләр аркасында, ата-ана (законлы вәкиле) баланы белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмага кабул итү турында гариза биргән вакытка нинди дә булса документлар тапшыру мөмкин булмаган очракта, ата-ана (законлы вәкил) гаризасы нигезендә баланы белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмага кабул итәргә тәкъдим ителә.

Аерым очракларда (әгәр бала ДХР, ЛХР, Украина территорияләреннән конкрет бала мәнфәгатьләрен тәкъдим итәргә законлы хокукы булмаган туганы яки башка зат озатуында килсә), баланы белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмага гомуми белем алуга бала хокукын тәэмин итүдә кызыксынучы туганының яисә башка затның гаризасы нигезендә яисә 14 яшькә җиткән баланың шәхси гаризасы нигезендә кабул итәргә тәкъдим ителә.».

2. Әлеге карарны Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырырга. (/http:pravo.tatarstan.ru).

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Ф.Ф.Петуховага йөкләргә.

Җитәкче А.Н. Макаров